БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
7 июнь 2022 ел

**КАРАР**
№ 133

**Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. 2010 елның 19 февралендәге 169 номерлы карар белән расланган Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1. 1 пунктка «(алга таба – муниципаль хезмәткәрләр).» сүзтезмәсен өстәргә;

- 1.2. 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими яшәү урыннарыннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча) муниципаль хезмәткәргә, ял һәм бәйрәм көннәрен, шулай ук юлда булган көннәрне, шул исәптән юлдагы тукталыш вакытын да кертеп, командировкада булган һәр көн өчен түләнелә, Татарстан Республикасы территориясендә командировкада булган һәр көн өчен 400 сум күләмендә, Татарстан Республикасыннан читтә – 400 сум күләмендә, федераль әһәмияттәге Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Севастополь шәһәрләренә к омандировкага җибәрелгәндә 700 сум күләмендә түләнә»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесе Р.Х. Мөхәммәтҗановага йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач районы Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин